ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 49-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.А. Чубаров тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 49-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 207-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.А. Чубаров
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» 2002 елның 15 октябрендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 10; 2003, № 9 (II өлеш); 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 20 (I өлеш), 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2 статья. **Җәмәгатьчелек вәкилләре кандидатураларына таләпләр**

1. 35 яше тулган, югары юридик белеме булган, үзенең яман атын чыгарырлык гамәлләр кылмаган, дәүләт вазыйфаларын яисә муниципаль вазыйфаларны, дәүләт яисә муниципаль хезмәт урыннарын биләмәгән, оештыру-хокукый һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләре адвокат һәм нотариус булмаган Россия Федерациясе гражданнары җәмәгатьчелек вәкилләре итеп билгеләнеп куелырга мөмкин.
2. Җәмәгатьчелек вәкиленең чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булырга тиеш түгел.
3. Чит ил агентлары реестрына кертелгән зат җәмәгатьчелек вәкиле була алмый.»;

2) 4 статьяның 1 өлешендә:
а) 6 пунктта «гражданлыгы туктатылу» сүзләреннән соң «, чит дәүләт гражданлыгын (подданлыгын) алуы йә яшәүгә рөхсәт яисә Россия Федерациясе гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алуы» сүзләрен өстәргә;
б) түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

«13) җәмәгатьчелек вәкиленең чит ил агентлары реестрына кертелүе.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты федераль законнардагы үзгәрешләр нигезендә Татарстан Республикасының норматив хокукый базасын үстерү максатларында эшләнде.

2024 елның 24 декабрендә үз көченә кергән 2024 елның 13 декабрендәге 466-ФЗ номерлы Федераль закон белән судьяларның квалификация коллегиясендә әгъзасы – җәмәгатьчелек вәкиле вәкаләтләре зат чит ил агентлары реестрына кертелгән очракта вакытыннан алда туктатылу мөмкинлеге төгәлләштерелә, шулай ук җәмәгатьчелек вәкиленең чит дәүләт гражданлыгы (подданлыгы) йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булмаска тиешлеге билгеләнә.

Федераль законнардагы үзгәрешләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы законы проекты белән «Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» 2002 елның 15 октябрендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү күздә тотыла.

Закон проекты ике статьядан тора. 2 статьяда Татарстан Республикасы Законының рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керүе тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларны үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.